# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегенең Луковское авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2024 елның 15 ноябре № 12

Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 15 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелгән, түбәндәге сорау буенча:

Сез 2025 елда Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге Луковское авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын урнаштыру, ремонтлау, тоту (юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү, смета документларын төзү, төзелеш контроле үткәрү);
- Тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар өчен мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырту челтәрләрен тоту, смета документларын төзү, төзелеш контроле үткәрү).

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыелышында 21 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 13 кеше, бу 61,90% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенында 13 катнашучы тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

Югарыда әйтелгәннәргә нигезләнеп, гражданнар җыелышы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге Луковское авылында гражданнар җыены узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танылсын.

2. Гражданнар җыелышына чыгарылган мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танылсын.

3 2025 елда алынган акчалар түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелсен:

- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын урнаштыру, ремонтлау, тоту (юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү, смета документларын төзү, төзелеш контроле үткәрү);

- Тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар өчен мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырту челтәрләрен тоту, смета документларын төзү, төзелеш контроле үткәрү).

4. Гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Өтәшкә ав., Нагорная ур., 99а йорт (җирлек администрациясе бинасы), Өтәшкә авылы, Үзәк, 40а йорт (мәдәният йорты бинасы).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Зеленодольск муниципаль районы
Өтәшкә авыл җирлеге башлыгы А.А. Клопов